# 9 – Р − 2016

**1.** ***Менә ул якындагы блиндажга күчеп тора башлады, чөнки монда телефон бар иде. (Х.Камалов)*** **Иярен җөмләнең төрен билгеләгез.**

а) иярчен урын җөмлә
ә) иярчен сәбәп җөмлә
б) иярчен аергыч
в) иярчен хәбәр җөмлә

**2.** ***Кем сабыр, шул җаен табар. (Мәкаль)*** **Иярчен җөмләнең төрен билгеләгез.**

а) иярчен аергыч җөмлә
ә) иярчен хәбәр җөмлә
б) иярчен ия җөмлә
в) иярчен тәмамлык җөмлә

**3.** ***Син аңла: мондый әсәр язарга ярамый.*** **Иярчен җөмләнең төрен билгеләгез.**

а) аналитик　　　　б) аналитик-синтетик
ә) синтетик　　　　в) берсе дә түгел

**4.** ***Ул атасына охшаган ( ) күп сөйләми, эшли дә эшли. (Г.Әпсәләмов)*** **Җөмләдә җәя урынына тыныш билгесенең куелышы кайсы төркемдә дөрес күрсәтелгән?**

а) өтер куела
ә) сызык куела
б) ике нокта куела
в) бернинди дә тыныш билгесе куелмый

**5. Бирелгән җөмләләр арасында кушма җөмлә бармы? Булса, билгеләгез:**

а) *Аңламагач, таякладылар (кыйнадылар).*
ә) *Мин аңламагач сөйләмәдем.*
б) *Бер аңлатты, ике аңлатты, аннан сөйләвен дәвам итте.*
в) *Аңлашылмаган урыннарын күреп, кабат төшендерде.*

**6. Ш. Камалның әсәрен дөрес билгеләгез.**

а) “Буран алдыннан”　　　　б)“Буран басылгач”
ә) “Буранда”　　　　в) “Буран”

7. Һ. Такташ“Мокамай” поэмасында төп геройга болай эндәшә:

“*Мин ант итәм: һичбер вакытта да*
*Сине карак итеп сөйләмәм...*”.

Асылда Сыркыды авылы халкы Мокамайны нәрсә урлауда гаепләгән була?

а) Бер кием чабата　　　　б) Арба тәгәрмәчен
ә) Бер капчык он　　　　в) Күршенең әтәчен

**8. Татар әдипләреннән кем гомерендә дүрт мәртәбә фамилиясен алыштыра (Гөлзизин, Хәзрәтов, Кусинов, Туфан)?**

а) Туфан Миңнуллин　　　　б) Хәсән Туфан
ә) Рабит Батулла　　　　в) Роберт Миңнуллин

**9. Г. Исхакыйның “Җан Баевич” әсәренең жанрын билгеләгез.**

а) Сатирик комедия　　　　б) Сатирик водевиль
ә) Сатирик драма　　　　в) Сатирик трагедия

**10. Легенда латин теленнән кергән сүз. Ул нинди мәгънәгә ия?**

а) Язылырга тиеш дигәнне аңлата
ә) Укылырга тиеш дигәнне аңлата
б) Таратылырга тиеш дигәнне аңлата
в) Сөйләнергә тиеш дигәнне аңлата

# 10 – Р − 2016

**1. Алгы рәт сузык авазларыннан гына торган сүзләр рәтен билгеләгез:**
а) ә, у, е(э), ы, ү
ә) ү, а, о, и, ы, ә
б) а, у, е(э), ө, ы
в) ә, и, ү, е(э), ө
**2. *ъ* аеру билгесе булып килгән сүзне билгеләгез:**
а) тәкъдим
ә) микъдар
б) алъяпкыч
в) шәфәкъ
**3. Басымы беренче иҗеккә төшкән сүзләр рәтен билгеләгез:**
а) килә, кайтаваз, сибегез, җырлармын, баргач
ә) эшләгез, утырыгыз, кайтсын, кирәкми, кибәр
б) барыгыз, атла, байтак, выжылдау, көчлесең
в) гаять, бары, ләкин, никадәр, килмәгез, һичбер
**4. *Әнкәй* сүзе нинди принципка нигезләнеп язылган?**
а) фонетик принципка
ә) тарихи-традицион принципка
б) морфологик принципка
в) график принципка
**5. Латин алфавиты татар теленең рәсми алфавиты итеп кайчан кабул ителә?**
а) 1920 елда　　　　б) 1928 елда
ә) 1927 елда　　　　в) 1929 елда
**6. Шигъри юлларның авторын атагыз.**
“*Мәйданга ул аена бер чыгар иде,*
*Йөзеннән пәрдәсен ачып куяр иде,*
*Олугъ-кечек, бай һәм юксыл карар иде, −*
*Соңра бер ай ашамыйча түзәр имди.*”
а) Г. Кандалый　　　　б) С. Сараи
ә) Кол Гали　　　　в) Хисам Кятиб
**7. “Җөмҗөмә Солтан” поэмасының авторын билгеләгез.**
а) Кол Гали　　　　б) Мәхмүт Болгари
ә) Өмми Камал　　　　в) Хисам Кятиб
**8. С. Сараи “Сөһәйл вә Гөлдерсен” әсәрендә кызның егетне күргәч борылып куюын нәрсәгә тиңли?**
а) Күбәләкнең чәчкә тирәли әйләнүенә
ә) Кояш тирәли җирнең әйләнүенә
б) Сандугачның оясы тирәли әйләнүенә
в) Бүренең болан баласы тирәли әйләнүенә
**9. Газәл жанрының традицион тематикасын атагыз.**
а) Туган як　　　　б) Кемнедер чиксез мактау
ә) Мәхәббәт　　　　в) Аталар һәм балалар мөнәсәбәте
**10. Түбәндәге әсәрләрнең кайсысы Мөхәммәдьярныкы түгел?**
а) “Нәсыйхәт”　　　　б) “Төхфәи мәрдән”
ә) “Нуры содур”　　　　в) “Нәһҗел-фәрадис”

## 11 – Р − 2016

**1. Кайсы төркемдә тамыр дөрес күрсәтелгән?**

а) җырлау (җыр-) б) сөйлә (сөйлә-)

ә) шигърият (шиг-) в) уйларлык (уйла-)

**2. Исем ясагыч кушымчаларны билгеләгез:**

а) -ла/-лә, лан/-лән б) -чы/-че, -даш/-дәш

ә) -ча/-чә, -дай/-дәй в) -лы/-ле, -гы/-ге

**3. *Балакай, бәләкәй, дәү, тау, хикәят, әкият* сүзләре сүз ясалышының кайсы ысулы белән ясалган?**

а) сүзләрне кушу юлы белән

ә) сүз ясагыч кушымчалар ялгау юлы белән

б) бер сүз төркеменнән икенчесенә күчерү юлы белән

в) сүзләрнең аваз составын үзгәртү юлы белән

**4. Синтаксик ысул белән нинди сүзләр ясала?**

а) тамыр һәм ясалма

ә) кушма һәм парлы

б) кушма, парлы һәм тезмә

в) бары тик парлы

**5. Ымлыклар ярдәмендә нәрсә белдерелә?**

а) тавыш белдерелә

ә) теләк, ихтыяр белдерелә

б) хис, тойгы белдерелә

в) образ беледерелә

**6. Зөбәйдә һәм Мәхмүт Һ. Такташның нинди поэмасыннан?**

а) “Киләчәккә хатлар” б) “Мәхәббәт тәүбәсе”

ә) “Алсу” в) “Мокамай”

**7. Г. Ибраһимовның нинди әсәре “Фәхрине үтереп ташладылар” дигән җөмлә белән башланып китә?**

а) “Яз башы” б) “Яшь йөрәкләр”

ә) “Казакъ кызы” в) “Тирән тамырлар”

**8. Түбәндәге юлларның авторын атагыз.**

“*Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,*
*“Муса инде үлгән”, - дисәләр,*
*Син ышанма, бәгърем!*
*Мондый сүзне*
*Дуслар әйтмәс, сине сөйсәләр*”.

а) М. Мирза б) М. Мәһдиев

ә) М. Җәлил в) М. Әгъләмов

**9. Ф. Кәримнең “Разведчик язмалары”ндагы Акморат нинди милләт кешесе?**

а) Татар б) Рус

ә) Башкорт в) Төрекмән

**10. Г. Кутуйның “Тапшырылмаган хатлар” повесте дүрт хатка нигезләнгәне билгеле. Шул хатларның өченчесендә нинди вакыйгалар чагылыш тапкан?**

а) Галия белән Искәндәрнең очрашуы

ә) Галия белән Искәндәрнең өйләнешүләре; балалары тууы, аерылышулары

б) Галиянең Әдрәс авылына балалары белән эшкә баруы; врач булып эшли башлавы; авыл халкының хөрмәтен казануы.

в) Совет хатын-кызларының гүзәл образлары сурәтләнүе; Вәли белән Галиянең очраклы очрашулары